**Слайд 1**

**Исәнмесез, хөрмәтле коллегалар!**

Мин сезне үземнең мастер-классымда күрүемә шатмын.

Хәзер сезне әбием сөйләгән гыйбрәт белән таныштырып китәм. **(Сл.2)**

Бездә бер авыз һәм ике колак,димәк, без сөйләүгә караганда күбрәк тыңларга тиеш.Тик күзләр колаклардан өстәрәк урнашканнар,шуңа күрә без ышанганчы кузебез белән күрергә тиеш. Боларның барысы өчен дә баш мие бар,шуңа да без башта күреп,ишеткәннәрне сөйләгәнче уйларга тиеш.

**Кереш олеш.**

Безнең хәтер — бу бик зур хәзинә. Бу хәзинәгә кергәч, без бик күптөрле әйберләр белән очрашабыз. Кайсын сайлап алабыз? Әлбәттә, мавыктыргыч һәм кызыклысын.

**(Сл.3)** Бөек рус полководецы Суворов әйткәнчә: “Хәтер ул - бик күп каршылыклы акыл хәзинәсе, шуңа күрә андагы бар хәзинәне тиешле урынга дөрес итеп урнаштырырга кирәк”.

Аны ничек эшләргә? Бүген без сезнең белән шул турыда сөйләшербез.

Хәзерге вакытта балага бик күп мәгълүмат бирелә. Әлбәттә моның һәрберсен истә калдыру мөмкин дә түгел. Моннан начар өлгереш килеп чыгасы көн кебек ачык.

Укучылар арасында кызыксынмаучы балалар да бар. Шуның өчен укытуны нәтиҗәле һәм кызыклы итеп оештыруны һәрбер укытучының изге бурычы дип саныйм. Без барыбыз да һәр укучы үзенең уңышын күрүен, шәхси мөмкинлеген тоюын телибез.

Хөрмәтле хезмәттәшләрем, бүген мин сезнең белән укучыларга ничек тиз итеп истә калдырырга, җиңел үзләштерергә өйрәтүче эйдетика методының кайбер элементлары белән уртаклашам.

**Ә нәрсә соң ул эйдетика? (слайд 4)**

Грекчадан тәрҗемә иткәндә «эйдос» «**сурәт**» дигәнне аңлата.

**Фильм карау (Слайд 5)**

Ә хәзер минем соравыма җавап бирегез эле.

- Сезнең аш бүлмәсендәге стена нинди төстә?

Әлбәттә,сез бу сорауга кыенсынмыйча җавап бирәчәксез.

- Бу сорауга җавапны бик нык уйладыгызмы? Әллә үзегезнең аш бүлмәсендәге стена күз алдына китерү дә җиттеме?

**(Сл. 6)** Безнең баш миенең һәм хәтер эшчәнлегенең үзенчәлеге шунда: һәрбер информация “эйдос”лар ярдәмендә истә кала. Мәсәлән, әгәр без **өй, компьютер, бүлмә** дип эйтәбез икән, һәр кешенең үзенең эчке күзаллавы туа

һәм һәр кеше үз өен, үз бүлмәсен, үз компьютерын күз алдына китерә. Шушы сурәтләр аша без мәгълүматны истә калдырабыз.

**<u>Менә шушы эйдетика алымы була да инде.</u>**

**(Сл.7)** Эйдетика алымын кулланып , балаларга килешләрне истә калдыру өчен дә бу алым ярдәм итә.

“ **Булат ишеккә юнәлә тышка чыгып утыра**”.

Шулай ук

-текстлар өстендә эшләгәндә,

-шигырьләрне өйрәнгәндә,

-исем, фамилияләрне истә калдыру өчен уңай.

Эйдетиканың сере нәрсәдә соң? Барысы да бик гади генә. Истә калдыру өчен нәкъ менә сурәтләүне уен аша алып баруда. Иң мөһиме: истә калдыру түгел, ә күрү һәм күзаллау. Без нәрсәне дә белмәсәк, «күз алдыма да китерә алмыйм!» дип әйтәбез. Ә күз алдына китермибез икән, димәк истә калдыра алмыйбыз.

Ничек итеп үзебезгә кирәкле мәгълүматны истә калдырырга соң? Чынлап та, нәрсә соң ул «истә калдыру. Ә ничек истә калдырырга? Һичшиксез, һәр яңаны үзләштерер өчен моны үз башыңнан үткәрергә кирәк.

***Төп өлеш.***

Ә менә сез сүзләрне эзлекле рәвештә җиңел генә истә калдыра аласызмы? Әйдәгез әле тикшереп карыйк!

Без сезнең белән хәзер сүзләр төркемен истә калдырырбыз.Мин сүзләрне әйткәндә берәү дә бер нәрсә дә язмый, бары тик тыңлап кына тора.

***Мәтрүшкә-бака яфрагы-бөтнек-үги ана яфрагы-ромашка-кычыткан***

- *Кем ничә сүз истә калдырды? (әйтәләр)* - Бик яхшы!

Ә хәзер без эйдетика алымын кулланып карыйк. Әйдәгез, уйнап алабыз.

Үзегезгә уйнарга, ял итәргә мөмкинлек бирегез,ә мин үз чиратымда сезнең барысы да уңай килеп чыгар дип ышанып калам.

Ә уенның кагыйдәләре болай:

1) Утырабыз, карыйбыз, тыңлыйбыз.
2) Үз-үзеңә комачаулау тыела.
3) Әйтелгән сүзне кабатларга ярамый.

Мин сезгә рәсемнәр күрсәтәм һәм сүзләр әйтәм. Бу рәсемнәр сүзне истә калдыру өчен ачкыч булып торалар. Уенның исеме “Сурәтле ачкыч”

Сез әзерме? Кәефләрегез ничек? Әйдәгез башлыйбыз.**(Слайд 9)**

**1. Учак** (чөнки агачлар урталыкта учак кебек “ яналар”)
**2. Шәм**
**3. Алка**
**4.Чебурашка**
**5.Телефон** (балачакта уйный идек)
**6. Мунча**
**7. Валюта(**әбиләр өйрэнэ)
**8. Көзге.**
**9.Боз сөңгесе.**

- Кәефләрегез ничек?
Ә хәзер киресенчә мин рәсемнәрне күрсәтәм, ә сез сүзләрне әйтегез.

**Чебурашка –эт**
**Валюта-әби. Алар ничәү иделәр?**
**Телефон**

- Чынлап та, Сез 1 нче биремгә караганда сүзләрне генә түгел, ә рәсемнәрне дә күбрәк истә калдырдыгыз.

**Нәтижэ:** Без баш мие эшчәнлеге нәтиҗәсендә һәм табигый сәләтебез белән бу биремне үти алдык.

- Һәм тагын бер уен. Пиктограмма - истә калдыруның тагын бер уңышлы ысулы. Пиктограмма— үзебез уйлап гадиләштерелгән билгеләр, тамгалар.

Мин Сезгә әкиятне шул метод ярдәмендә ничек итеп җинел генә истә калдырырга мөмкин булуын курсәтергә телим.

Шат,кунелле нәни гномнар яшәгән ди. Алар Кыш Бабайны бүләкләр белән сөендермәкче булганнар.Гномнар чанага утырганнар да әкияти таудан шуып төшеп киткәннәр. Каршыларында күңелсез музыкантларны очратканнар. Аларның уен кораллары җимерелгән икән. Гномнар аларга барабан,кубыз,гармон биргәннәр. Юл кырыенда моңсу кар бабай утырган. Аның кулында себерке генә булган . Бу шат гномнар аңа чыршы бүләк иткәннәр. Ә урманнан Кыш Бабай килеп чыккач, алар куркышып калганнар. Ә Кыш Бабай аларга : «Мин беләм, сезнең яхшы эшләрегез- иң зур бүләк» дигән.
Истә калдырырга җайлы булдымы?

## Йомгаклау.

Кайвакыт мин үзем дә гаҗәпләнәм, нинди искиткеч ачыш ясый укучыларым дәресләрдә. Алардан хәтта өйрәнергә була,чөнки аларда фантазия искиткеч!
Юкка гына әйтмәгәннәр бит “Балаларга мөмкинлек кенә бирергә кирәк, алар тауларны да урыныннан күчерәчәк” дип.